КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 декабрь г.Казань № 1133

Төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларда яшәмәгән физик затлар төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә булган өчен алына торган түләү турында

«Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $5^1$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларда яшәмәгән физик затларга махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә булган өчен түләү билгеләү һәм түләү алудан азат итү очракларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 13 июлендәге 1039 номерлы карары белән расланган Махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларда яшәмәгән физик затларга махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә булган өчен түләү билгеләү һәм түләү алудан азат итү очракларын билгеләү кагыйдәләренең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларда яшәмәгән физик затлар төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә булган өчен алына торган түләү күләмен;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә булган өчен түләү алудан азат ителә торган физик затлар категорияләрен.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 11 декабрь, 1133 нче
карары белән расланды

## Төбәк әһәмиятендәге махсус саклаa торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларда яшәмәгән физик затлар төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрендә булган өчен алына торган түләү күләме

| Т/с | Төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территориясе | Төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә бер тапкыр булган өчен түләү күләме, сум | Төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә булган өчен түләү алуга вәкаләтле оешма |
|---|---|---|---|
| 1 | Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы | 100 | «Хайваннар дөньясын саклап калу өлкәсендә инновацион технологияләрне кертү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 11 декабрь, 1133 нче
карары белән расланды

Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган
табигать территорияләрендә
булган өчен түләү алудан азат ителә торган
физик затлар категорияләре

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларда яшәмәгән физик затларга махсус саклана торган табигать территорияләрендә булган өчен түләү билгеләү һәм түләү алудан азат итү очракларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 13 июлендәге 1039 номерлы карары белән расланган Махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларда яшәмәгән физик затларга махсус саклана торган табигать территорияләрендә булган өчен түләү билгеләү һәм түләү алудан азат итү очракларын билгеләү кагыйдәләренең 5 пунктындагы «а» – «с» пунктчаларында күрсәтелгән затлардан тыш төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрендә булган өчен түләү алудан түбәндәгеләр азат ителә:

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре территориясендә хезмәт вазыйфаларын башкарганда Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының вазыйфаи затлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре территориясендә линия объектларына хезмәт күрсәтү чараларын, аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характерга ия башка хәлләрне бетерү чараларын гамәлгә ашыручы затлар;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре территориясендә аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә хайваннар дөньясыннан файдалануны гамәлгә ашыручы затлар;

шартнамәләр нигезендә төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре территориясенә хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы затлар;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләренең биологик төрлелеген, табигать комплексларын һәм объектларын өйрәнүгә һәм торгызуга, мәдәни мирас объектларын өйрәнүгә һәм саклауга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрүне, шулай ук төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре территориясендә экологиягә багышланган чаралар үткәрүне гамәлгә ашыручы затлар;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан җир һәм урман кишәрлекләренең милекчеләре, арендага алучылары, алардан файдаланучылар, шулай ук аларның төбәк әһәмиятендәге махсус

сакланыла торган табигать территорияләре территориясендә эшләр башкаручы хезмәткәрләре һәм аларның подряд оешмалары хезмәткәрләре;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре территориясендә урманнарны саклауда, яклауда һәм яңадан торгызуда катнашучы затлар.